**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**города Азнакаево Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре БАШЛЫГЫ**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592) 7-23-85
mailto:adm@aznakay.gov.tatarstan.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел. (885592) 7-24-83, факс (885592) 7-23-85
mailto:aznakay@tatar.ruE-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**"10" октябрь 2022 ел** **№290**

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пункты территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2022 елның 21 октябрендә 18.00 сәгатькә халык җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Азнакай шәһәре, Заводская урамы 1 йорт янында.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге торак пункты территориясенең шушы өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын уздыру өчен территориянең бер өлешенең чикләрен түбәндәге территорияләр чикләрендә расларга:

- Заводская тыкрыгы буенча 1 йорттан 12 а йорт.

3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 12 октябреннән дә соңга калмыйча, Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 14 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай

шәһәре башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә Заводская урамы 1 йорттан 12 а йортына кадәр яшәүче, сайлау хокукына ия гражданнар исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы “Азнакай шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә Заводская тыкрыгы 1 йорттан 12а йортына кадәр яшәүче гражданнарга массакүләм мәгълүмат чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"Сез, 2023 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы студентларыннан кала һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча үзара салым кертүгә ризамы:

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Заводская тыкрыгы 1 йорттан 12а йортына кадәр буенча җирле әһәмияттәге автомобиль юлларны карап тоту (юлларны асфальт-бетон белән каплау, төяү, ташу, асфальт-бетон салу эшләре өчен түләү).

« РИЗА» "КАРШЫ"

6. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 2 көн эчендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Башлык М.З. Шәйдуллин